| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.01.2025 ел Баулы шәһәре №6

2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча муниципаль программаны расларга

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2008 елның 10 ноябрендәге 799 номерлы, «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча кушымтада бирелә торган муниципаль программаны (алга таба – Программа) расларга.

2. Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан барлык милек формаларындагы учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә программаны гамәлгә ашыру чараларын күрергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Җитәкче Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 24 гыйнварындагы
6 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

# 2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча муниципаль программа

Баулы шәһәре– 2025 ел

# 1. ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | 2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча муниципаль программа (алга таба – Программа) |
| Программаны уйлап чыгаруга нигезләр | - 2001 елның 30 декабрендәге 197-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;<br>- Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең демографик сәясәт концепциясен раслау турында» 2007 елның 9 октябрендәге 1351 номерлы Указы;<br>- «Производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү турында» 1998 елның 24 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законы;<br>- «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законы;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2008 елның 10 ноябрендәге 799 номерлы карары;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм «Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары |
| Программаны заказчы | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп уйлап табучылар | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге;<br>Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы |
| Программаның максаты | Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан предприятиеләр һәм оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри хәвеф-хәтәрләрен киметү максатларында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту |

| | |
|---|---|
| Программаның бурычлары | 1) Баулы муниципаль районы предприятиеләрендә, оешмаларында һәм учреждениеләрендә хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышына анализ;<br>2) производствода бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны профилактикалау һәм кисәтү;<br>3) хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәүне тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>4) предприятиеләр/оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең хезмәтне саклау буенча укыту һәм белемнәрен, хезмәтне саклау таләпләрен тикшерү системасын камилләштерү;<br>5) Баулы муниципаль районы предприятиеләрендә, оешмаларында һәм учреждениеләрендә хезмәтне саклауны мәгълүмати һәм норматив тәэмин итүне оештыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2025-2027 елларга |
| Программаны башкаручылар | - Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы;<br>- Баулы муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы барлык милек формаларындагы предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр. |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | 2025-2027 елларда программа чараларын үтәүгә бюджеттан тыш һәм бюджет чыганаклары исәбеннән барлыгы 57 078,9 мең сум күләмендә финанс чыгымнары планлаштырыла, шул исәптән еллар буенча:<br>2025 елга:<br>Баулы муниципаль районы бюджеты – 756,3 мең сум;<br>башка чаралар (бюджеттан тыш) – 26 238,2 мең сум;<br>2026 елга:<br>Баулы муниципаль районы бюджеты – 334,7 мең сум;<br>башка чаралар (бюджеттан тыш) – 14 212,4 мең сум;<br>2027 елга:<br>Баулы муниципаль районы бюджеты – 334,7 мең сум;<br>башка чаралар (бюджеттан тыш) – 15 202,6 мең сум.<br>Күрсәтелгән чыганаклардан бүлеп бирелә торган акчалар күләме фаразлау характерында була һәм, ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә Программа чаралары исемлеге, аларны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары төгәлләштерелеп, билгеләнгән тәртиптә ел саен төзәтелергә тиеш.<br>Программада чагылдырылган чараларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре программа чараларына ассигнованиеләрне тиешле финанс елына район бюджетында раслау шарты белән бүлеп бирелергә мөмкин. Тиешле финанс елына район |

| | |
|---|---|
| | бюджетында программа чараларына ассигнованиеләр булмаса, финанслау район бюджетына өстәмә керемнәр булганда һәм (яисә) бюджетның башка чыгымнары буенча бюджет ассигнованиеләре кыскартылганда гамәлгә ашырылырга мөмкин. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2027 елга түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>1) производствода зыян күрүчеләр саны - 0 кеше;<br>2) предприятиеләрдә, оешмаларда һәм бюджет учреждениеләрендә хезмәтне саклау өчен җаваплы җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча укулар узу дәрәҗәсе - 100%;<br>3) производствода бәхетсезлек очраклары саны һәм һөнәри авырулар алу – 0 кеше;<br>4) производствода имгәнүләр һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсе — 0 %;<br>5) хезмәткәрләрне зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары, җитештерү факторлары йогынтысыннан яклау дәрәҗәсе - 100%;<br>6) уңайсыз хезмәт шартларында эшләүчеләр саны -0 кеше. |

## 2. Программаны гамәлгә ашыру юлы белән хәл ителә торган проблемаларга характеристика һәм анализ

Хезмәтне саклау хезмәт эшчәнлеге процессында имин хезмәт шартларын тәэмин итүдә мөһим шарт булып тора.

Хәзерге икътисадый шартларда эш урыннарында куркынычсызлыкны һәм тиешле хезмәт шартларын тәэмин итү җәмгыятьнең социаль-икътисадый иминлегенә сизелерлек йогынты ясый.

Хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе системасы хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга, хезмәт эшчәнлеге барышында кешенең иминлеген, сәламәтлеген һәм эшкә сәләтлелеген тәэмин итү буенча хокукый, социаль-икътисадый, оештыру-техник, санитария-гигиена, дәвалау-профилактика һәм башка чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән. Хезмәтне саклау өлкәсендә төп бурыч – эш бирүчегә йөкләнгән хезмәт бурычларын үтәгәндә хезмәткәрләрнең иминлеген тәэмин итү.

Кеше сәламәтлеге социаль кыйммәтләр системасында алдынгы урынны алып тора һәм дәүләтнең иң мөһим ресурсы буларак карала. Һөнәри авырулар, травматизм бөтен дәүләткә зыян китерә, һәм бу һөнәри хәвеф-хәтәр дәрәҗәсен киметүгә һәм хезмәт шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән нәтиҗәле чаралар таләп итә.

Хезмәтне саклау турында Россия Федерациясе законнарында, хезмәтне саклау буенча, шул исәптән гигиена һәм Хезмәт медицинасы буенча башка норматив хокукый актларда беркетелгән сәламәт һәм имин хезмәт шартларына хезмәт ияләренең хокуклары практикада һәрвакытта да тәэмин ителми, чөнки аларны гамәлгә ашыру механизмнары юк.

Баулы муниципаль районында хезмәтне саклау белән муниципаль идарә итү Россия Федерациясе Конституциясенең, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының тиешле нормалары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының тиешле закон чыгару һәм башка норматив актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Бүгенге көндә бөтен Россиядә җитештерү травматизмы, производствода үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очраклары җитди проблема булып тора. Юкка гына ел саен 28 апрель Бөтендөнья хезмәтне саклау көне булып тормый.

Баулы муниципаль районы территориясендә 372 хуҗалык субъекты теркәлгән, шул исәптән түбәндәге өлкәләрдә:

- төзелеш– 41;
- сәүдә, автотранспорт чараларын ремонтлау – 29;
- эшкәртү производствасы – 22;
- транспортировкалау һәм саклау – 22;
- авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык һәм балык тоту – 17;
- файдалы казылмаларны алу – 9;
- мәгариф – 49;
- башкалар – 183.

Баулы муниципаль районында Татарстан Республикасы муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы эшли. Координация советының төп бурычлары булып производствода имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны киметү һәм профилактикалау, хезмәтне саклау шартларын яхшырту, Баулы муниципаль районы предприятиеләрендә, оешмаларында һәм учреждениеләрендә хезмәтне саклау өлкәсендә мәгълүмати һәм норматив тәэмин итү, хезмәтне саклауны пропагандалау тора.

Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чараларын финанслау Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 226 статьясы нигезендә эш бирүченең бурычы булып тора. Хезмәтне саклау чараларына чыгымнар предприятиеләр җитәкчеләренең хезмәтне саклауга һәм үз хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген саклауга мөнәсәбәте, димәк, хезмәтне саклау белән идарә итүнең гамәлдәге системасының нәтиҗәлелеге индикаторы булып тора.

Баулы муниципаль районы дәрәҗәсендә программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру зарурлыгын билгеләүче мөһим факторлар булып хезмәткә сәләтле халыкның тормыш сыйфатын яхшырту һәм сәламәтлеген саклау тора.

Халыкның сәламәтлеген саклау һәм үлү очракларын киметү эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: эшләүче халыкның хезмәт шартларын һәм хезмәтен саклауны яхшырту, һөнәри хәвеф-хәтәрне профилактикалау һәм киметү буенча чаралар күрү; эшләүчеләргә диспансеризация һәм профилактик тикшерү үткәрү.

## 3. Программаның максаты һәм төп бурычлары, аны гамәлгә ашыру сроклары

Программаның максаты-хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту, Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан предприятие һәм оешма хезмәткәрләренең һөнәри хәвеф-хәтәрләрен киметү.

Программаның төп бурычлары:

- предприятиеләрдә һәм оешмаларда хезмәтне саклау белән идарә итү системасына һөнәри куркынычлар белән идарә итү механизмнарын кертү;
- хезмәтне саклауның норматив-хокукый базасын камилләштерү;

- хезмәтне саклау хезмәткәрләрен заманча укыту технологияләре нигезендә өзлексез әзерләү;

- хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау;

- эшче халыкка дәвалау-профилактика хезмәте күрсәтүне камилләштерү.

Программаны гамәлгә ашыру сроклары: 2025-2027 еллар.

4. Программа чараларын нигезләү
һәм аларны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чаралары закон таләпләреннән, программаларны гамәлгә ашыруның уңай тәҗрибәсеннән чыгып, шулай ук әлеге программа кысаларында куелган бурычлардан чыгып формалаштырылды. Баулы муниципаль районында 2025-2027 елларга хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча программа чаралары исемлеге Программаның 2 нче кушымтасында бирелгән.

Программа сроклар һәм башкаручылар буенча килештерелгән үзара бәйле чаралар комплексы буларак формалаштырылган, ул төп максатларга ирешүне тәэмин итә – җитештерүдәге уңайсыз факторларга бәйле рәвештә хезмәткә сәләтле халыкның үлемен киметү һәм сәламәтлеген югалтуын, җитештерүдә хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау системасын камилләштерү, хезмәткәрләргә медик-профилактик хезмәт күрсәтү системасын булдыру һәм үстерү.

Баулы муниципаль районы территориясендә хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау өлкәсендә төп максат-гражданнарның имин хезмәт шартлары дәрәҗәсен күтәрү.

2025-2027 елларда программа чараларын үтәүгә бюджеттан тыш һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына барлыгы 57.078, 9 мең сум күләмендә финанс чыгымнары планлаштырыла.

Күрсәтелгән чыганаклардан бүлеп бирелә торган акчалар күләме фаразлау характерында була һәм, ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә Программа чаралары исемлеге, аларны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары төгәлләштерелеп, билгеләнгән тәртиптә ел саен төзәтелергә тиеш.

Программада чагылдырылган чараларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре программа чараларына ассигнованиеләрне тиешле финанс елына Баулы муниципаль районы бюджетында раслау шарты белән бүлеп бирелергә мөмкин. Тиешле финанс елына район бюджетында программа чараларына ассигнованиеләр булмаса, финанслау район бюджетына өстәмә керемнәр булганда һәм (яисә) бюджетның башка чыгымнары буенча бюджет ассигнованиеләре кыскартылганда гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Һәр чара буенча финанс ресурслары күләме чараны гамәлгә ашыру срогының озын булуыннан, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр бәясенең планлаштырыла торган минималь зурлыгыннан һәм аларның күләмнәреннән чыгып билгеләнә.

5. Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре
һәм максатчан индикаторлар (күрсәткечләр)

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә:

- һөнәри авырулар һәм производствода имгәнүләр дәрәҗәсенең кимүе;

- производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар куркынычы кимү;

- хезмәткә сәләтле халык арасында производствода травматизм яисә һөнәри авыру аркасында үлүчеләр санының кимүе;

- производствода имгәнү яки һөнәри авыру нәтиҗәсендә алынган инвалидлык дәрәҗәсенең кимүе;

- Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмаларда эшләүчеләргә уңайлы хезмәт шартлары тудыру;

- авыр, зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын киметү;

- хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторлары йогынтысыннан яклау дәрәҗәсен арттыру;

- эшләүчеләрнең иминлеген арттыру максатларында хезмәтне саклау чараларына эш бирүчеләр тарафыннан бүлеп бирелә торган акчаларны арттыру;

- эш вакыты югалтуларын киметү исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;

- хезмәтне саклау өлкәсендә җитәкчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү.

Программаның максатларына ирешү һәм бурычларын хәл итү программаның 1 нче кушымтасында китерелгән максатчан индикаторлар (күрсәткечләр) белән бәяләнә.

Әлеге максатчан индикаторлар (күрсәткечләр) хезмәтне саклауның төп күрсәткечләреннән гыйбарәт, алар ел саен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәтне саклау өлкәсендәге органнары, Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясе, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, дәүләт учреждениеcе - Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге һәм дәүләт Татарстан Республикасы буенча статистика.

Әлеге күрсәткечләрнең динамикасы башкарылган чараларның нәтиҗәлелеген күрсәтә.

## 6. Механизм реализации Программы

Программаны гамәлгә ашыру барышында Баулы муниципаль районында хезмәтне саклау буенча Координация советы Программа чараларын төп башкаручыларның эшчәнлеген координацияли, программаны гамәлгә ашыруның барышын һәм бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалануны тикшереп тора.

Программаны җаваплы башкаручы программа чараларын гамәлгә ашыруны, хисап белешмәләрен җыюны, анализлауны һәм әзерләүне тәэмин итә, шулай ук программаны үтәү нәтиҗәләре турында билгеләнгән тәртиптә хисап тота.

Финанслау күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру срокларын күрсәтеп, программа чаралары исемлеге Программаның 2 нче кушымтасында бирелгән.

## 7. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

2027 елга программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге:

- производствода бәхетсезлек очракларыннан, җитештерү белән бәйле авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметергә;

- производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплауга чыгымнарны киметергә;

- производствода имгәнү яки һөнәри авыру аркасында инвалидлык дәрәҗәсен киметү һәм шуңа бәйле рәвештә сәламәтлек саклау өлкәсендәге чыгымнар;

- эш вакыты югалтуларын киметү исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга;

- производствода алынган җәрәхәт яисә авырулар аркасында төп хезмәткәрләрне вакытлыча алмаштыручы тәҗрибәсез хезмәткәрләр эксплуатацияләгәндә килеп чыккан төзексезлекләр аркасында җитештерүдә җиһазларны ремонтлау һәм алмаштыру чыгымнарын киметергә;

- хезмәтне саклау өлкәсендә җитәкчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрергә.

---

2025-2027 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында хезмәт шартларын
һәм хезмәтне саклау буенча
муниципаль программага
1 нче кушымта

Төп максатчан индикаторлар (күрсәткечләр)

| № п/п | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берә млеге | 2024 ел (факт) | 2025 ел (план) | 2026 ел (план) | 2027 ел (план) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Производствода зыян күрүчеләр саны | чел. | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2. | Хезмәтне саклау буенча укулар узган җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең дәрәҗәсе | % | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 3. | Производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар саны | ед. | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4. | Производствода имгәнүләр һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсе | % | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 5. | Хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторлары йогынтысыннан яклау дәрәҗәсе | % | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 6. | Уңайсыз хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр саны | чел. | 0 | 0 | 0 | 0 |

_______________

2025-2027 елларга Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районында хезмәт шартларын
һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча
муниципаль программасына
2 нче кушымта

)25-2027 елларга Баулы муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау өчен программа чаралары исемлеге

| № п/п | Башкаручылар | Башкаручылар | Финанслау чыганаклары (мең сум) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 ел | | 2026 ел | | 2027 ел | |
| | | | Җирле бюджет | Башка чыганаклар | Җирле бюджет | Башка чыганаклар | Җирле бюджет | Башка чыганаклар |
| 1. | Район территориясендә урнашкан җирле үзидарә органнарын, профсоюз оешмаларын, предприятиеләрне һәм оешмаларны җәлеп итеп, семинарлар, киңәшмәләр, күргәзмәләр, смотр-конкурслар оештыру һәм үткәрү юлы белән хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чараларын гамәлгә ашыру | Хезмәтне саклау буенча Координация советы, предприятиеләр һәм оешмалар | - | 15,0 | - | 20,0 | - | 18,0 |
| 2. | Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча республика һәм район чараларын (семинарлар, киңәшмәләр, күргәзмәләр, конференцияләр һ. б.) оештыру һәм аларда катнашу | муниципаль учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар | - | 23,0 | - | 24,0 | - | 24,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Хезмәтне саклау темасына социаль реклама конкурсы яисә балалар рәсемнәре конкурсы үткәрү | Хезмәтне саклау буенча Координация советы, предприятиеләр һәм оешмалар | - | 10,0 | - | 0,0 | - | 10,0 |
| 4. | Ел саен уздырыла торган Бөтендөнья хезмәтне саклау көнен үткәрү | Хезмәтне саклау буенча Координация советы, предприятиеләр һәм оешмалар | - | 45,0 | - | 71,0 | - | 68,0 |
| 5. | Эш бирүчеләргә хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау, заманча куркынычсызлык чараларын пропагандалау һәм гамәлгә кертү, хезмәтнең алдынгы ысулларын һәм алымнарын тарату мәсьәләләрендә методик һәм практик ярдәм күрсәтү | Хезмәтне саклау буенча Координация советы | - | - | - | - | - | - |
| 6. | Билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән тикшеренү лабораторияләрен җәлеп итеп, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында эш урыннарында җитештерү мохите факторларын контроль үлчәүләрне оештыру | предприятиеләр һәм оешмалар | - | 624,4 | - | 436,0 | - | 447,0 |
| 7. | Хезмәт шартларын махсус бәяләү чараларын оештыру | муниципаль учреждениеләр, | 144,9 | 73,6 | - | 284,0 | - | 100,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | предприятиеләр һәм оешмалар | | | | | | |
| 8. | Хезмәткәрләргә диспансеризация, медицина тикшерүе уздыру чараларын оештыру | муниципаль учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар | 334,7 | 4122,0 | 334,7 | 2512,0 | 334,7 | 2728,0 |
| 9. | Тавыш, радиация дәрәҗәсен үлчәү чараларын оештыру | предприятиеләр һәм оешмалар | - | 14,2 | - | 15,4 | - | 16,6 |
| 10. | Район оешмалары, шул исәптән бюджет учреждениеләре җитәкчеләрен һәм белгечләрен вакытлыча укытуны һәм хезмәтне саклау буенча белемнәрен тикшерүне оештыру | муниципаль учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар | 226,7 | 343,0 | - | 299,0 | - | 339,0 |
| 11. | Хезмәткәрләрне махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итү | предприятиеләр һәм оешмалар | 50,0 | 20838,0 | - | 10420,0 | - | 11320,0 |
| 12. | Массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау, предприятиеләргә хезмәтне саклау өлкәсендәге закон һәм норматив-хокукый документлардагы үзгәрешләр турында мәгълүмат җиткерү | Хезмәтне саклау буенча Координация советы, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты | - | - | - | - | - | - |
| 13. | Хезмәтне саклау буенча Координация советы эшен оештыру, киңәшмәләр, утырышлар үткәрү | Координационный совет по охране труда, | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты | | | | | | |
| 14. | Баулы муниципаль районы сайтында https://www.bavly.tatarstan.ru «Хезмәтне саклау» бүлеген алып бару | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты | - | - | - | - | - | - |
| 15. | Вакытлы басмаларны хезмәтне саклау буенча белешмә-методик һәм тематик материалларга, шул исәптән электрон ресурсларга рәсмиләштерү | предприятиеләр һәм оешмалар | - | 97,0 | - | 97,0 | - | 97,0 |
| 16. | Хезмәтне саклау темасына мәгълүмат стендлары, күрсәткечләр эшләү һәм урнаштыру | предприятиеләр һәм оешмалар | - | 33,0 | - | 34,0 | - | 35,0 |
| Барлыгы: | | | 756,3 | 26238,2 | 334,7 | 14212,4 | 334,7 | 15202,6 |